ГЛАВА ШЕМОРБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422667, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, с. Шеморбаш,
Советская ул., дом 47,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ШОМЫРБАШ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422667,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Шомырбаш авылы,
Совет урамы, 47 нчы йорт.

Тел.: (84361) 20-415, факс: (84361) 20-415, эл.адрес: Smrb.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

08 ноября 2021 года　　　　　с.Шеморбаш　　　　　№ 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Р“ Шоморбаш авыл җирлеге” Шомарбаш авылы, Таулар авылы, Алан-Полян авылы, хэм Кзыл-Йолдызский лесхоз авылы торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында.

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Шомарбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шоморбаш авыл җирлегенең Шоморбаш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 18 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шоморбаш авыл җирлегенең Таулар авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 18 ноябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шоморбаш авыл җирлегенең Алан-Полян авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 19 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.
4. 3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шоморбаш авыл җирлегенең Кзыл-Йолдызский лесхоз авыл торак пунктында үзара

салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 19 ноябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.

4. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шоморбаш авыл җирлегенең Шоморбаш авылы, Таулар авылы, Алан-Полян авылы, хэм Кзыл-Йолдызский лесхоз авылы торак пункларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре, тумыштан инвалид, беренче группа инвалид) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Шомырбаш авылындагы Совет, Север, Мәктәп урамнарында юлларны төзекләндерү эшлере өчен.
- Шомырбаш авылында тирән насос сатып алу һәм урнаштыру.
- Шомарбаш авылында су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү
- Таулар авылындагы Совет, Ленин, Салкын Чишмя, Совет, Набережный урамнарында юлларны төзекләндерү эшлере өчен.
- Таулар авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру
- Таулар авылында су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү
- Алан-Полян авылындагы Я.Емельянова, Центр, Нагорный, Ленин урамнарында юлларны төзекләндерү эшлере өчен.
- Алан-Полян авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру
- Алан-Полян авылында тирән насос сатып алу һәм урнаштыру
- Алан-Полян авылында су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү.
- Кзыл- Йолдызский лесхоз авылындагу Центр, Урман, Парк урамнарында юлларны төзекләндерү эшлере өчен.
- Кзыл- Йолдызский лесхоз авылда су башнясын ремонтлау
- Кзыл- Йолдызский лесхоз авылда су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

5. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

“Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шоморбаш авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сафин